**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

«30» июль 2020 ел № 186

**Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 14 ноябрендә кабул ителгән 167нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунчаавыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 14 ноябрендә кабул ителгән «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» гы 167 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советының 2015 нче елның 11 сентябрендә № 207, 2018 нче елның 30 октябрендә № 128, 2019 нчы елның 21 мартында №147, 2019 нчы елның 18 ноябрендә № 168 кабул ителгән карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) өченче абзацтагы 2 пунктның 1 пунктчасындагы «бирелгән» сүзен һәм «дачный» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары һәм Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**Дүрт-Мунча авыл җирлеге башлыгы** **Р.Т.Ситдиков**